СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.200, с. Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366) 52-3-93, факс (84366) 52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Кәче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 03 » август 2021 ел № 29

**Кәче авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 16 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү һәм хакында**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Кәче авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Кәче авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 сентябрендәге 16 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Д. Шаһиәхмәтов